**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы һәм 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составына Заводская Светлана Александровнаны – «Мәнфәгатьләрен үз вәкилләре аша белдерү ихтыяҗы, менталь тайпылышлары һәм башка төрле авырулары булган инвалид балаларның һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалидларның ата-аналары бөтенроссия оешмасы» гомумроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлекчәсе рәисен (килешү буенча) кертергә;

б) Совет әгъзасы В.М. Матяшның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гаулстон».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 21 август
№ ПУ-479